КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 июль г.Казань № 534

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләре буенча агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләре буенча агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Минераль ашламалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Органик продукция җитештерүне үстерү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Читлектәге кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплау өчен җәнлек үрчетү хуҗалыкларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Нәселле терлекчелеккә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы

бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен.»;

әлеге карарга Минераль ашламалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен, Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен, Органик продукция җитештерүне үстерү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен, Нәселле терлекчелеккә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен, Авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин